**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

БОЕРЫК ______________ РАСПОРЯЖЕНИЕ №_________

Актаныш муниципаль районында яшәүче хәрби хезмәткәрләрнең, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) Актаныш муниципаль районы гражданнарының гаилә әгъзаларына адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Актаныш муниципаль районының финанс һәм матди мөмкинлекләреннән чыгып, махсус хәрби операциядә катнашучыларга яисә аларның гаиләләренә түбәндәге хезмәтләр күрсәтелергә мөмкин:

- бәйрәмнәрдә азык-төлек җыелмалары,
- торак йортны яисә мунчаны мич белән җылыту кулланылганда, мохтаҗларны 3 елга 1 тапкыр утын белән тәэмин итү (торак шартларын тикшерү акты нигезендә).

Хезмәттән файдаланучыларның категорияләре:

1. Актаныш районы Хәрби комиссариаты аша чакырылган, Актаныш районында яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучылар (Актаныш районы Хәрби комиссариаты исемлеге нигезендә),
2. Актаныш районында яшәүче, махсус хәрби операциядә катнашучының гаиләсе (хатыны, балигъ булмаган балалары),
3. Актаныш районында яшәүче, махсус хәрби операциядә катнашучының әти-әнисе,
4. Актаныш районында яшәүче, демобилизацияләнгән, хезмәттән азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучылар (махсус хәрби операция ветераннары) ,
5. Актаныш районында яшәүче, махсус хәрби операциядә һәлак булучының гаиләсе (хатыны, балигъ булмаган балалары),
6. Актаныш районында яшәүче, махсус хәрби операциядә һәлак булган катнашучының әти-әнисе,
7. Актаныш районында яшәүче, махсус хәрби операциядә хәбәрсез югалган катнашучының (хәбәрнамә булганда) гаиләсе (хатыны, балигъ булмаган балалары),
8. Актаныш районында яшәүче, махсус хәрби операциядә хәбәрсез югалган катнашучының (хәбәрнамә булганда) әти-әнисе.

Хезмәт күрсәтү өчен кандидатураны карaганда, өстенлек махсус хәрби операциягә чакырылу вакытына яшәү урыны булып тора.

Махсус хәрби операциядә һәр катнашучыга (яки хатыны, яки балигъ булмаган балалары, яки ата-аналары) бер азык-төлек җыелмасы каралган.

Район Башлыгы Л.Р. Зарипов